ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## “Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 3 пунктында “республиканың максатчан программаларын” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт программаларын” сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 3 пунктында “республиканың максатчан программаларын” сүзләрен “Татарстан Республикасы дәүләт программаларын” сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяда:
а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Татарстан Республикасы милкендә түбәндәге музей әйберләре һәм музей тупланмалары бар:
1) Федераль закон үз көченә кергәнче Татарстан Республикасы милкендә булган, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына сатып алынган;
2) Россия Федерациясе законнарында каралган нигезләр буенча дәүләт музейлары һәм Татарстан Республикасы карамагындагы башка дәүләт оешмалары тарафыннан сатып алынган.”;
б) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:
“5. Татарстан Республикасы милкендәге һәм Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кертелгән музей әйберләре һәм музей тупланмалары дәүләт милкеннән алынырга тиеш түгел.”;

4) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9 статья. **Музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән идарә итү**

1. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кертелгән музей әйберләре һәм музей тупланмалары белән идарә итү мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы (алга таба – мәдәният өлкәсендәге федераль башкарма хакимият органы) һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше составына кертелгән һәм дәүләт милке булган музей әйберләре һәм музей тупланмалары Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт музейларына һәм муниципаль музейларга, башка оешмаларга түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин.

3. Милкендә, хуҗалыгында яисә файдалануында Россия Федерациясе Музей фондының составына кертелгән музей әйберләре һәм музей тупланмалары булган музейлар, башка оешмалар, физик затлар музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын туплауны, исәпкә алуны, саклауны һәм алардан файдалануны оештыруның мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган бердәм кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының физик сакланышын, шулай ук мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органында музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына реставрация эшләрен үткәрү хокукына федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә аттестация узган затлар тарафыннан реставрация эшләре үткәрелүне;

2) музей әйберләренә һәм музей тупланмаларына бирелгән исәпкә кую билгеләре һәм аларның саклау маркировкалары булуны кертеп, музей әйберләренең һәм музей тупланмаларының иминлеген;

3) музей әйберләре һәм музей тупланмалары исәпкә куелуны, аларга бәйле исәпкә кую документлары алып барылуны һәм саклануны.”;

5) 10 статьяның 1 өлешендә “мәдәният өлкәсендә дәүләт җайга салуы йөкләнгән федераль орган” сүзләрен “мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы” сүзләренә алмаштырырга;

6) 18 статьяның 1 өлешендә “бүтән дәүләт учреждениеләренә” сүзләрен “бүтән дәүләт оешмаларына” сүзләренә алмаштырырга;

7) 20 статьяның 2 өлешендә:

а) 3 пунктта “музей әйберенең” сүзләреннән соң “яисә музей тупланмасының” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

“4) Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләрнең булуы.”;

8) 24 статьяның 3 өлешендә “мәдәни мирас объектларын саклауның, куллануның, популярлаштыруның һәм дәүләт саклавының республика максатчан программаларында” сүзләрен “мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларында” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 11 гыйнвар
№ 1-ТРЗ